**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«11» апрель 2024 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны тоту, вак таш сатып алу, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юл полотносы профилен үзгәртү белән чокырлау өчен хезмәтләр күрсәтү, юлларны карап тоту, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юлларга тыгыз нигез салу һәм грейдировкалау буенча хезмәтләр шул исәптән сезонлы тоту);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы территориясен төзекләндерү);

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (-Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы территориясен чистарту һәм төзекләндерү).

Халык җыенында рәислек итүче Р.Г. Хисамов

Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов